КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 5 март г.Казань № 174

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, тормышта авыр хәлдә калган балаларны карап тору һәм тәрбияләү» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында

Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең сыйфатын яхшырту, алардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче оешмаларга таләпләрне стандартлаштыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, тормышта авыр хәлдә калган балаларны карап тору һәм тәрбияләү» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны, тормышта авыр хәлдә калган балаларны карап тоту һәм тәрбияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты турында» 2016 ел, 30 декабрь, 1059 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны, тормышта авыр хәлдә калган балаларны карап тоту һәм тәрбияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты турында» 2016 ел, 30 декабрь, 1059 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 19 ноябрь, 1052 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 ел, 18 апрель, 486 нчы.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер–министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 ел, 5 март, 174 нче карары белән расланды

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, тормышта авыр хәлдә калган балаларны карап тору һәм тәрбияләү» дәүләт хезмәте сыйфаты стандарты

I. Дәүләт хезмәтен алучыларның категорияләре (шулай ук ташламалы)

Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче һәм ятим балалар өчен оешмага кабул ителгән авыр тормыш хәлендә булган балаларга, ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга, балаларг ятим балалар өчен оешма уставы белән билгеләнгән тәртиптә күрсәтелә (алга таба – балалар):

ятим балалар – ата-аналарының икесе дә яки бердәнбере вафат булган 18 яшькә кадәрге затлар;

ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар – ата-аналарының бердәнбере яки икесе дә ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителү, аларның ата-ана хокуклары чикләнү, ата-аналарының хәбәрсез югалган, эшкә яраксыз (яки чикләнгән эшкә яраклы) дип танылуы, үлгән дип игълан ителүе, суд тарафыннан ата-ана каравыннан мәхрүм калу факты билгеләнү, ата-аналарының иректән мәхрүм итү җәзасын үтәүче учреждениеләрдә җәза үтәве, җинаять кылуда шикләнелүчеләр һәм гаепләнүчеләрне сак астында тоту урыннарында булуы, ата-аналарының балаларын тәрбияләүдән яки аларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклаудан баш тартуы, ата-аналарының балаларын белем бирү оешмаларыннан, медицина оешмаларыннан, социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмалардан алудан баш тартуы, шулай ук бердәнбер ата-ананың яки икесенең дә билгесез булуы, закон нигезендә билгеләнгән башка очракларда ата-ана каравыннан мәхрүм калган дип танылуы сәбәпле ата-аналарының бердәнбере яки икесенең дә каравыннан мәхрүм калган 18 яшькә кадәрге затлар;

авыр тормыш хәлендә булган балалар – ятим балалар, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар; инвалид балалар; сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар, ягъни физик һәм (яки) психик үсештә кимчелекләре булган балалар; кораллы һәм милләтара конфликтлар, экологик һәм техноген һәлакәтләр, табигый бәла-казалар корбаннары булган балалар; качаклар һәм мәҗбүри күченүчеләр гаиләләреннән булган балалар; экстремаль шартларда калган балалар; көч куллану корбаннары булган балалар; тәрбия колонияләрендә иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче балалар; девиант (җәмгыять өчен куркыныч) тәртипле укучылар өчен белем бирү оешмаларында булган, тәрбия, укыту өчен махсус шартлар таләп итүче һәм махсус педагогик якын килү кирәк булган (ачык һәм ябык төрдәге махсус уку-тәрбия учреждениеләрендә) балалар; аз керемле гаиләләрдә яшәүче балалар; тәртиптә тайпылышлары булган балалар; тормыш эшчәнлеге объектив рәвештә катлаулы шартлар нәтиҗәсендә бозылган һәм әлеге шартларны мөстәкыйль рәвештә яки гаилә ярдәме белән җиңә алмаган балалар.

## II. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең хокукый нигезе

2.1. Дәүләт хезмәте түбәндәге закон, норматив хокукый актлар нигезендә күрсәтелә:

1989 елның 20 ноябрендә Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль Ассамблеясе тарафыннан расланган Бала хокуклары турында конвенция;

Россия Федерациясе Конституциясе;

Россия Федерациясе Гаилә кодексы;

«Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

«Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Балигъ булмаганнарның караучысыз калуын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлекне гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре турында» 2009 елның 18 маендагы 423 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру турында» 2009 елның 19 маендагы 432 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалар эшчәнлеге турында һәм аларда ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны урнаштыру турында» 2014 елның 24 маендагы 481 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары;

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының «Балалар һәм яшьләр ялын, аларны тәрбияләүне, укытуны һәм сәламәтләндерүне оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән СП 2.4.3648-20 нче санитария кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Конституциясе;

Татарстан Республикасы Гаилә кодексы;

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар хәлен яхшырту буенча беренче чираттагы чаралар турында» 2003 ел, 16 май, 266 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килүен бәяләүне уздыру тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары;

ятим балалар өчен оешмалар уставы;

дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча башка норматив хокукый актлар, билгеләнгән кагыйдәләр һәм нормалар.

2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон белән көйләнми.

## III. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе дәүләт хезмәтен күрсәтү сыйфатының түбәндәге күрсәткечләре белән бәяләнә:

| Т/с | Сыйфатны бәяләү күрсәткече исеме | Үлчәү берәм-леге | Исәпләү формуласы | Исәпләү вакытында кулланыла торган белешмәләр буенча мәгълүмат чыганагы | Авыр-лык коэф-фициенты | Чик күрсәт-кече |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе органнары тарафыннан хисап елында тикшерүләр уздырганда ачыкланган санитария законнарын бозу саны | берәм-лек | контроль-күзәтчелек органнарының күрсәтмәләрендә теркәлгән бозулар саны | ятим балалар өчен оешмалар хисаплылыгы | 8 | 0 |
| 2. | Хезмәтнең сыйфаты һәм үтемлелеге белән канәгатьләндерелгән дәүләт хезмәтен алучылар өлеше | про-цент | $\frac{О_к + О_д}{2 \times О_{общ}} \times 100\%$,<br><br>кайда:<br>$О_к$ – хезмәтләр сыйфатыннан канәгать булган сораштырылганнар саны;<br>$О_д$ – хезмәтләрнең уңайлылыгына канәгать булган сораштырылганнар саны;<br>$О_{гом}$ – сораштырылганнарның гомуми саны | дәүләт хезмәте күрсәтүләрдән файдаланучыларны сораштыру нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 9 | 90 |
| 3. | Тормыш эшчәнлеге иминлеген бозу очраклары саны | берәм-лек | ятим балалар, мәктәп яны территориясе өчен оешманың матди базасының | тикшерү нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 6 | 0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | торышы канәгатьләнерлек булмауга бәйле рәвештә белем бирү процессында катнашучыларны имгәтү очраклары исәпкә алына | | | |
| 4. | Штатлы хезмәткәрләр белән комплектлану | про-цент | $\frac{Ч_ф}{Ч_{шр}} \times 100\%$,<br><br>монда:<br>$Ч_ф$ – ятим балалар өчен оешмалар хезмәткәрләренең факттагы саны;<br>Чшр – ятим балалар өчен оешманың штат расписа-ниесе белән каралган хезмәткәрләре саны | ятим балалар өчен оешмалар хисаплылыгы | 6 | 100 |
| 5. | Дәүләт хезмәте алучыларның нигезле шикаятьләре өлеше | про-цент | $\frac{Ж_о}{Ж} \times 100\%$,<br><br>монда:<br>$Ж_о$ – хисап чорында кергән дәүләт хезмәтен алучылар-ның нигезле шикаятьләре саны;<br>Ж – хисап чорында кергән дәүләт хезмәтен алучылар-ның гомуми шикаятьләре саны | дәүләт хезмәтен алучы-ларның шикаятьләрен һәм алар буенча кабул ителгән чаралар турында мәгълүматны анализлау | 9 | 0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Хокук бозу кылган балалар өлеше | про-цент | $\frac{A}{B} \times 100\%$,<br><br>монда:<br>А – хокук бозу кылган балалар саны;<br>В – балаларның гомуми саны | ятим балалар өчен оешмалар хисаплылыгы | 7 | 0 |
| 7. | Өстәмә белем бирү оешмаларына, түгәрәкләргә һәм башкаларга йөргән балалар өлеше | про-цент | $\frac{A}{B} \times 100\%$,<br><br>монда:<br>А – өстәмә белем бирү системасында шөгыльлә-нүче балалар саны;<br>В – балаларның гомуми саны | ятим балалар өчен оешмалар хисаплылыгы | 7 | 90 |
| 8. | Ятим балалар өчен оешмаларда эшләүче педагогларның югары һәм беренче квалификацион категориягә ия өлеше | про-цент | $\frac{A}{B} \times 100\%$,<br><br>монда:<br>А – югары һәм беренче квалификацион категорияле педагоглар саны;<br>В – ятим балалар өчен оешмада педагогларның гомуми саны | ятим балалар өчен оешмалар хисаплылыгы | 6 | 90 |

## IV. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат стандарты үтәлмәүгә карата шикаятьләр бирү, аларны теркәү һәм карап тикшерү тәртибе

4.1. Балалар яки балаларның законлы вәкилләре тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозу, дәүләт хезмәте сыйфаты Стандарты үтәлмәү турында шикаять (алга таба – шикаять) язма рәвештә кәгазьдә, электрон рәвештә ятим балалар өчен оешмага бирелә. Ятим балалар өчен оешма җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына бирелә.

Шикаятьне теркәү ятим балалар өчен оешманың эш алып бару кагыйдәләренә ярашлы рәвештә шикаять килгән көннән өч календарь көннән дә соңга калмыйча башкарыла.

4.2. Ятим балалар өчен оешманың, ятим балалар өчен оешма җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьне почта аша, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша, ятим балалар өчен оешманың рәсми сайты, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (www.gosuslugi.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (uslugi.tatarstan.ru) аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук балаларны яки балаларның законлы вәкилләрен шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

4.3. Шикаять законнар белән билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.

4.4. Ятим балалар өчен оешмага яки Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына килгән шикаять теркәлгән көннән башлап 15 эш көне эчендә каралырга тиеш, әгәр ятим балалар өчен оешманың документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны бозуга яки хаталарны төзәтү срокларын бозуга шикаять бирелгән булса – теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

4.5. Шикаятьне законнар нигезендә карау нәтиҗәләре буенча карар кабул ителә һәм аны кабул иткән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, язмача һәм балалар яки балаларның законлы вәкиле теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

4.6. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылган очракта, балаларга яки балаларның законлы вәкилләренә җавапта дәүләт хезмәте күрсәтүдә ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатыннан ятим балалар өчен оешмалар тарафыннан башкарылган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм балаларга яки балаларның законлы вәкилләренә башкарырга кирәкле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

4.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип табылган очракта, балаларга яки балаларның законлы вәкилләрнә кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

4.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

4.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

## V. Дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе

5.1. Ятим балалар өчен оешмаларның эшчәнлеген контрольдә тоту Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, шулай ук үз вәкаләтләренә ярашлы башка дәүләт органнары тарафыннан башкарыла.

5.2. Дәүләт хакимияте органнары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килүен бәяләүне уздыру тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## VI. Дәүләт хезмәтен түләүле яки бушлай күрсәтү турында мәгълүмат

Дәүләт хезмәте тулы дәүләт тәэминаты нигезендә бушлай күрсәтелә.